**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2019 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен бирү турында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм:**

2019 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен һәм «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премиясе лауреаты» исемен түбәндәгеләргә бирергә:

1. «Кан тамыры системасы авыруларын диагностикалау һәм дәвалауда инновацияле технологияләр» хезмәте өчен:

Игнатьев Игорь Михайловичка, медицина фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең кан тамырлары хирургиясе юнәлеше буенча баш белгече, проектның җитәкчесенә;

Бредихин Роман Александровичка, медицина фәннәре докторы, доцент, «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең кан тамырлары хирургиясе бүлекчәсе мөдиренә;

Әхмәтҗанов Рөстәм Вил улына, медицина фәннәре кандидаты, «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең кан тамырлары хирургиясе бүлекчәсе табибы-йөрәк-кан тамырлары хирургына.

2. «Нефть һәм нефть продуктлары әзерләү һәм эшкәртү процессларында һава агымына көйләнгән, көчле һава агымы җайланмалары булган инновацияле аппаратларны эшләү һәм аларны сәнәгатьтә киң кулланышка кертү» хезмәте өчен:

Бахтизин Рамил Назиф улына, физика-математика фәннәре докторы, профессор, Башкортостан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, «Уфа дәүләт нефть техник университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректорына, хезмәтнең җитәкчесенә, Уфа шәһәре;

Авзалетдинов Айдар Габбас улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте башкарма аппаратының нефтьне әзерләү һәм тапшыру хезмәте әйдәүче инженерына, Әлмәт шәһәре;

Алиев Мехрали Мирзали улына, техник фәннәр докторы, «Әлмәт дәүләт нефть институты» дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Нефть-газ җиһазлары һәм машина төзү технологияләре» кафедрасы профессорына, Әлмәт шәһәре;

Галиәкбәров Вил Фәйзулла улына, техник фәннәр докторы, профессор, «НТ-Центр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорына, Уфа шәһәре;

Нургалиев Роберт Заһит улына, «Әлмәт дәүләт нефть институты» дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручыга, Әлмәт шәһәре;

Сидоров Георгий Маркеловичка, техник фәннәр докторы, «Уфа дәүләт нефть техник университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Нефть һәм газ технологияләре» кафедрасы профессорына, Уфа шәһәре;

Трубкин Сергей Анатольевичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте «Нурлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең нефтьне әзерләү һәм тапшыру хезмәте әйдәүче экспертына, Нурлат шәһәре;

Яхин Булат Әхмәт улына, «НТ-Центр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры урынбасарына, Уфа шәһәре.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 22 ноябрь
№ ПУ-701